**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 6 апрель № 218

г. Казань

2015 елда эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау тәртибен раслау турында

2015 елда Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2015 елда эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Тәртипне куллану мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирү Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\218.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 6 апрель, 218 нче
карары белән расланды

# 2015 елда эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау ТӘРТИБЕ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. 2015 елда эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасының хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2015 ел, 18 март, 162 нче карары белән расланган «2015 елга Татарстан Республикасының хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасын тормышка ашыру һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча инвалидларны эшкә урнаштыру һәм эш бирүчеләрдә инвалидларның эш урыннарын саклау юлы белән инвалидларның эш белән социаль тәэмин ителешен тәэмин итү максатларында эшләнде.

2. Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыруга федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына 2015 елда субсидияләр бирү һәм бүлү турында» 2015 ел, 22 гыйнвар, 35 нче карары нигезендә эшләнде.

3. Тәртип эш бирүчегә бу Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән эш бирүчеләрдә эшләүче инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау күләмен һәм механизмын билгели.

4. Инвалидларның хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы түбәндәге теләсә кайсы оештыру-хокук рәвешендәге һәм милек рәвешендәге оешмаларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына (алга таба – эш бирүче) бирелә:

инвалидларның эш урыннарын саклап калу ихтыяҗы булган (эш бирүче хезмәткәрләренә эштән азат итү куркынычы янаса (эш тукталып тору, тулы булмаган эш режимы кертелү, хезмәткәрләрне эштән азат итү чаралары үткәрелү, эш хакын сакламыйча яллар бирү, икътисадый, технологик, техник яки оештыру характерындагы сәбәпләр буенча эшне вакытлыча туктатып тору);

агымдагы елда халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча инвалидны эшкә урнаштыручы.

5. Эш бирүчегә бер айда бер инвалид хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау күләме 2014 елның IV кварталында Татарстан Республикасында эшкә яраклы халык өчен билгеләнгән, эш бирүчедә гамәлдә булган хезмәт өчен түләү шартлары яки хезмәт шартнамәсе нигезендә эшләгән вакыт өчен пропорциональ рәвештә бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәре суммасына арттырылган яшәү минимумы күләменнән артык була алмый.

Эш бирүчегә инвалид хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау чоры 6 айдан да артмаска тиеш.

Эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплауның гомуми күләме, эш бирүчедә эшләүче инвалидлар саныннан, бер айда бер инвалид хезмәте өчен түләү чыгымнарын каплау күләменнән һәм инвалидларның эш хакына чыгымнарны каплау күләменнән чыгып, бу Тәртипнең 5 нче пунктындагы беренче абзац нигезендә билгеләнә.

## II. Эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау тәртибе һәм шартлары

6. Эш бирүчегә 2015 елда инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыруга федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына 2015 елда субсидияләр бирү һәм бүлү турында» 2015 ел, 22 гыйнвар, 35 нче карары белән расланган Россия Федерациясе субъектлары хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыруга федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына 2015 елда субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләре нигезендә бирелә торган Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр акчасы исәбеннән бирелә.

7. Эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау турында шартнамә төзү өчен эш бирүче агымдагы елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне теркәп, Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру урынындагы дәүләт учреждениесенә (алга таба – үзәк) Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) раслаган форма буенча гариза тапшыра:

эш урыннарын саклап калу зарурлыгы нигезләвен. Килеп туган вәзгыятькә бәйле рәвештә, халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тулы булмаган эш вакыты билгеләнү һәм (яки) хезмәткәрләрне эштән азат итү үткәрелү, эш хакы сакланмыйча яллар бирелү турындагы боерык күчермәсен һәм (яки) хезмәткәрләрнең эшләмичә торырга мәҗбүр булуын раслый торган документлар

(икътисадый, технологик, техник яки оештыру характерындагы сәбәпләр буенча эшне вакытлыча туктатып тору турындагы боерык күчермәсен; эш вакытын исәпкә алу табеле күчермәсен) – инвалидларның эш урынын саклап калу ихтыяҗы булган эш бирүче өчен;

эш бирүчегә гаризада күрсәтелгән чор өчен инвалидлар хезмәтенә түләү чыгымнарын каплауга кирәкле акча күләме исәп-хисабын;

бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәренең исәпләнгән суммасы исәп-хисабын;

инвалидны эшкә кабул итү турындагы боерык (приказ) күчермәсен – агымдагы елда халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча эшкә урнаштырганда;

халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы күчермәсен – агымдагы елда халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча эшкә урнаштырганда;

фамилияләрен, исемнәрен, аталары исемнәрен, гариза керткән көнгә биләгән вазыйфаларын күрсәтеп, эш бирүчедә эшләүче хезмәт өчен түләү чыгымнары капланачак инвалидлар исемлеген.

Эш бирүченең гаризасы эш белән тәэмин итү үзәгенә кергән көнендә теркәлә.

Күрсәтелгән вакыттан соңрак кертелгән гаризалар каралмый.

8. Эш бирүче үз теләге белән гаризага түбәндәге документларны теркәргә хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык күчермәсен;

юридик затны салым органында исәпкә кую турындагы таныклык күчермәсен;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан чыгарма;

Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан чыгарма яки мондый чыгарманың нотариатта таныкланган күчермәсен (индивидуаль эшмәкәр өчен);

эш бирүченең барлык дәрәҗәдәге бюджетларга һәм бюджеттан тыш фондларга салымнар һәм җыемнар түләү буенча бурычларын үтәве турында белешмә кәгазен;

эш бирүчегә карата бетерү яки бөлгенлек процедуралары үткәрелмәү турында белешмә кәгазен.

9. Эш бирүче бу Тәртипнең 8 нче пунктында күрсәтелгән документларны кертмәгән очракта, эш белән тәэмин итү үзәге әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибендә соратып ала.

10. Эш белән тәэмин итү үзәге гаризаны теркәлгән көненнән эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә карый.

11. Гаризаны карау йомгаклары буенча эш белән тәэмин итү үзәге эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау турында шартнамә (алга таба – шартнамә) төзү йә шартнамә төзүдән баш тарту хакында карар кабул итә.

Эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплауның максатка ярашлы булмавы турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

эш бирүче бу Тәртипнең 4 нче пунктында билгеләнгән шартларга туры килмәү;

бу Тәртипнең 7 нче пунктында күрсәтелгән документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы билгеләнү;

эш бирүче бетерелү яки бөлгенлек стадиясендә булу, шул исәптән арбитраж суд тарафыннан эш бирүчене мөлкәтсез (бөлгенлеккә төшкән) дип тану турында һәм конкурс эшен ачу хакында карар кабул ителү.

12. Эш белән тәэмин итү үзәге гариза теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә эш бирүчегә кабул ителгән карар турында хәбәрнамә җибәрә.

Карар уңай булса, эш белән тәэмин итү үзәге карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көн эчендә эш бирүче белән шартнамә төзи.

Шартнамә формасы Министрлык тарафыннан раслана.

Шартнамәдә түбәндәгеләр карала:

эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга акча күчерү тәртибе һәм вакытлары;

инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен алынган акчаны, әлеге акчаны алганда билгеләнгән шартлар бозылган очракта, кире кайтару тәртибе һәм вакытлары;

хисап финанс елында күрсәтелгән максатларга бүлеп бирелгән файдаланылмый калган акчаны агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары;

акча алучыларның бу Тәртип һәм төзелә торган шартнамә шартларын үтәүләренә һәм акча алучыларның аларны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүләренә Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан тикшерүләр гамәлгә ашыруга эш бирүченең риза булу шарты.

13. Министрлык тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында күздә тотылган акча чикләрендә Министрлыкка билгеләнгән лимитлар нигезендә акчаны эш белән тәэмин итү үзәкләре исәпләренә күчерә.

14. Эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен акча күчерү бу Тәртиптә һәм шартнамәдә күздә тотылган шартларда эш белән тәэмин итү үзәге исәбенә акча кергәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 7 көн эчендә эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

15. Эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау эш бирүченең эш хакы түләүгә булачак чыгымнарын авансләу тәртибендә яки эш бирүче түбәндәге документларны керткәндә айга кимендә бер тапкыр эш бирүче әлеге максатларга фактта тоткан чыгымнар өчен гамәлгә ашырыла:

инвалидның (инвалидларның) шәхси тернәкләндерү программасы күчермәсен яки, инвалидлык төркемен күрсәтеп, инвалидлык билгеләнү фактын раслый торган белешмә кәгазе күчермәсен (инвалидның (инвалидларның) шәхси тернәкләндерү программасы булмаганда);

инвалидларны эшкә кабул итү турындагы боерык күчермәсен – агымдагы елда эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча эшкә урнашканда;

эш вакытын исәпкә алу табеле күчермәсен;

исәп-хисап ведомосте (исәпләнгән эш хакы суммасы турында) күчермәсен – инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплаганда аванс түләве рәвешендә;

бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәре буенча исәпләнгән сумманың ирекле рәвештә төзелгән исәп-хисабын;

түләү ведомосте (эш хакының түләнгән суммасы турында) күчермәсен яки кредит учреждениеләрендә инвалидларның шәхси исәпләренә эш хакы суммасын күчерү хакындагы түләү йөкләмәсенең таныклаган күчермәсен – хезмәт өчен түләүгә фактта тотылган чыгымнарны каплаганда;

бюджеттан тыш дәүләт фондларына күчерелгән иминият кертемнәре турындагы түләү йөкләмәсе күчермәсен - хезмәт өчен түләүгә фактта тотылган чыгымнарны каплаганда.

Документларның күчермәләре эш бирүченең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан раслана һәм мөһер белән беркетә (юридик зат өчен).

16. Эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен аванс түләве рәвешендә бүлеп бирелгән һәм  агымдагы елның 31 декабренә кадәр файдаланылмый калган акча 2016 елның беренче 10 эш көне эчендә эш белән тәэмин итү үзәгенә кире кайтарып бирелергә тиеш.

## III. Эш бирүчегә инвалилар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга бүлеп бирелгән акчаны сарыф итүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе

17. Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

18. Министрлык квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 еннән дә соңга  калмыйча, финанслар белән тәэмин ителү чыганагы субсидия булган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында һәм эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидиядән файдалануның нәтиҗәлелеге буенча максатчан күрсәткечләр мәгънәләренә ирешү хакында Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү федераль хезмәтенә һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына хисап кертә.

19. Әлеге акчаның агымдагы елның 31 декабре хәленә карата файдаланылмый  калган өлеше гамәлдәге законнарда каралган тәртип һәм вакытлар нигезендә федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә кире кайтарылырга тиеш.

20. Эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга бүлеп бирелгән бюджет акчасыннан максатчан файдалануны тикшерүдә

тоту эш белән тәэмин итү үзәкләре һәм Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## IV. Йомгаклау нигезләмәләре

21. Эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга бүлеп бирелгән акча түбәндәге очракларда эш белән тәэмин итү үзәгенең тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә бу акчаны алучы тарафыннан эш белән тәэмин итү үзәгенә кире кайтарылырга тиеш:

эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга бүлеп бирелгән акчадан максатчан файдаланылмаганда;

эш бирүченең инвалидлар хезмәте өчен түләү буенча дөрес булмаган мәгълүматлар кертү фактлары ачыкланганда;

шартнамәдә каралган башка шартлар үтәлмәгәндә.

Эш бирүчегә инвалидлар хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга бүлеп бирелгән акчадан максатчан файдаланылмаса, ул максатчан файдаланылмаган суммада кире кайтарылырга тиеш.

22. Әлеге акчаны кире кайтару вакыты бозылса йә аны Татарстан Республикасы бюджеты һәм федераль бюджет керемена үз ирекләре белән кире кайтарудан баш тартсалар, эш белән тәэмин итү үзәге бу Тәртипнең 21 нче пунктындагы беренче абзацта билгеләнгән вакыт чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 7 көн эчендә бу акчаны законнарда билгеләнгән тәртиптә федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемена түләттерү чараларын күрә.

---

F:\KARAR\2015\218-1.doc